СОВЕТ УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮСӘЛИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
№ 4-37

Карар
от 20.11.2018г

**2018 нче елның 18 ноябрендә җирле референдумда кабул ителгән карарны теркәү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 24.04.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2018 елның 18 ноябрь көнендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәсендә:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне , су чыгаруны оештыру:

Усали торак пунктында су белән тәэмин итү системасын үзгәртү:

2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:

- Владимир торак пунктында Дуслык урамы,Беренче май урамы буенча баручы юлны, Югары Берсут торак пунктында Җиңү урамы буенча баручы юлны, Бөрсет-Сукачы торак пунктында Яшьләр урамы, Мәктәп урамы

буенча баручы юлны , Усали торак пунктында Беренче май урамы буенча баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау;
- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ » « ЮК »

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориаль сайлау комиссиясенең «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Усали авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре турында»2018 елның 19 ноябрендәге 926 номерлы карарын теркәргә.

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башлыгы А.И.Зиатдиновка йөкләргә.

СОВЕТ УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Мамадыш муниципаль районы
Үсәли авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе : А.И.Зиатдинов